КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 июль г.Казань № 554

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 34 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 34 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 758 нче; 2015 ел, 25 апрель, 288 нче; 2015 ел, 3 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 22 гыйнвар, 33 нче; 2017 ел, 20 гыйнвар, 15 нче; 2018 ел, 27 июнь, 524 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Э.Р.Камалованы, Г.Р.Нигъмәтуллинаны, С.Г.Персованы, Г.Ә.Шәрипованы чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Кәбир улы Абдуллинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Илдар кызы Әдһәмованы;

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Мөниб кызы Әсәдуллинаны;

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Олеся Александровна Балтусованы (килешү буенча);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Николаевич Гущинны;

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Евгеньевич Ивановны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы урынбасары Елена Александровна Кондратьеваны;

«Россия пенсионерлар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге идарәсе рәисе Любовь Николаевна Мишинаны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының мәдәният министры урынбасары Дамир Данил улы Натфуллинны;

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Тимур Җәүдәт улы Сөләймановны;

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Ринат кызы Фазлееваны;

Татарстан Республикасының мәдәният министры урынбасары Ленар Сәетҗан улы Хәкимҗановны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин